КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 8 декабрь г.Казань № 1197

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 22 апрель, 275 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасының Муниципаль берәмлекләр советы һәм Татарстан Республикасы муниципаль районнары (шәһәр округлары) арасында Татарстан Республикасы муниципаль районнарының (шәһәр округларының) җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең планлаштырыла торган мәгънәләренә ирешү турында килешүләр төзү тәртибенә 2 нче кушымтага үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасының Муниципаль берәмлекләре советы һәм Татарстан Республикасы муниципаль районнары (шәһәр округлары) арасында Татарстан Республикасы муниципаль районнарының (шәһәр округларының) җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең планлаштырыла торган мәгънәләренә ирешү турында килешүләр төзү тәртибен раслау хакында» 2015 ел, 22 апрель, 275 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министр-лар Кабинетының 2015 ел, 6 июль, 494 нче; 2016 ел, 15 февраль, 73 нче; 2016 ел, 7 ноябрь, 823 нче; 2017 ел, 29 декабрь, 1093 нче; 2018 ел, 22 сентябрь, 828 нче; 2019 ел, 12 апрель, 281 нче; 2019 ел, 29 июль, 629 нчы; 2020 ел, 25 август, 737 нче; 2021 ел, 19 апрель, 257 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә

алып) расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасының Муниципаль берәмлекләре советы һәм Татарстан Республикасы муниципаль районнары (шәһәр округлары) арасында Татарстан Республикасы муниципаль районнарының (шәһәр округларының) җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең планлаштырыла торган мәгънәләренә ирешү турында килешүләр төзү тәртибенә 2 нче кушымтага, аңа түбәндәге эчтәлекле 28 – 29 пунктларны өстәп, үзгәреш кертергә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «28. | Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында балаларны туган (татар) телендә укыту һәм тәрбияләү белән колачлау өлеше, процент | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы | ел саен | $V = \frac{A}{B} \times 100,$<br>монда:<br>A – мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында туган (татар) телендә укытыла һәм тәрбияләнә торган балалар саны;<br>B – мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында татар теле туган тел булган балаларның гомуми саны |
| 29. | Гомуми белем бирү оешмаларында балаларны туган (татар) телендә укыту һәм тәрбияләү белән колачлау өлеше, процент | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы | ел саен | $V = \frac{A}{B} \times 100,$<br>монда:<br>A – гомуми белем бирү оешмаларында туган (татар) телендә укытыла һәм тәрбияләнә торган балалар саны;<br>B – гомуми белем бирү оешмаларында татар теле туган тел булган балаларның гомуми саны». |

Татарстан Республикасы<br>Премьер-министры А.В.Песошин